РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

26.09.2017 № 1235-п

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы
Башкарма комитетының 2016 елның 07 маендагы 565-п
номерлы карары белән расланган Спорт чараларында
катнашучыларны һәм хезмәт күрсәтүче персоналны
матди тәэмин итүгә акчалар тоту тәртибенә һәм
нормаларына үзгәрешләр кертү турында

Спортны үстерүгә ярдәм итү, спортчыларның эшчәнлеген кызыксындыру максатларында Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставы, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты нигезендә югары спорт нәтиҗәләренә ирешү өчен

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 07 маендагы 565-п номерлы «Спорт чараларында катнашучыларны һәм хезмәт күрсәтүче персоналны матди яктан тәэмин итүгә акчалар тоту тәртибен һәм нормаларын раслау турында» карары белән расланган Спорт чараларында катнашучыларны һәм хезмәт күрсәтүче персоналны матди яктан тәэмин итүгә акчалар тоту тәртибенә һәм нормаларына (2016 елның 07 маендагы 565-п номерлы карарның үзгәрешләрен исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә (алга таба - Тәртип):
- Тәртипнең 4 пунктындагы 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«

| | | |
|---|---|---|
| 1 | Саба районы территориясендә ашату | 300 гә кадәр |
| | ТР һәм РФ территориясендә туклану | 300 |
| | ТР һәм РФ территориясендә министрлыклар һәм башка югарырак оешмалар боерыклары, нигезләмәләре, регламентлары һәм хатлары нигезендә туклану | 900 га кадәр |

».

1. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

Саба муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы,
муниципаль район башкарма комитеты
җитәкчесенең социаль мәсьәләләр
буенча беренче урынбасары Т.Г.Шәрәфиев